ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.11.2020 № 941

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу рәвешләрен билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 18 ноябрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашу рәвешләрен билгеләү максатларында Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу рәвешләре булып түбәндәгеләрне билгеләргә:

- эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;
- милектә булган биналарда һәм корылмаларда беренчел янгын сүндерү чаралары булу;
- янгын чыккан очракта кичекмәстән шул турыда янгын сагына хәбәр итәргә;
- янгын сүндерү сагы килгәнче кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгынны сүндерү буенча кулдан килгәнчә чаралар күрү;
- янгынны сүндергәндә янгын сүндерүчеләргә ярдәм күрсәтү;
- дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;
- законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларына янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тикшереп тору һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында үзләре карамагындагы җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны һәм корылмаларны тикшерү һәм күзәтчелек уздыру мөмкинлеге бирү.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән ирекле янгын сагы эшчәнлегендә катнашу формаларын билгеләү турында» 2013 ел, 18 февраль, 103 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы 125 нче янгын бүлеге» ФДКУ башлыгына йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Р.Р. Хәмзин